ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2017 елның 23 марты**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 623**

«Үз шәһәреңне уят» дигән язгы
социаль акция үткәрү турында

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен озак кышкы чордан соң тиешле эстетик тышкы кыяфәткә кертү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2017 елның 20 нче мартыннан 2017 елның 20 нче апреленә кадәр, кар эрегән саен, биналарның фасадларын, койма һәм саклагыч корылмаларны, тышкы төзекләндерү элементларын, кече архитектура формаларын, вывескаларын, реклама конструкцияләрен һәм башка объектларны чистарту һәм төзекләндерү буенча даими эш алып баруны игълан итәргә.
2. Кушымтада каралганча, объектларны чистарту һәм төзекләндерү буенча шәһәр штабы төзергә.
3. Шәһәр штабына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән шәһәр объектларын чистарту һәм төзекләндерү эшен координацияләүне тәэмин итәргә.
4. Милекнең оештыру - хокукый формаларына һәм милек формасына бәйсез рәвештә предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр җитәкчеләренә, биналар, корылмалар, элмә такталар, реклама конструкцияләре һәм башка объектлар хуҗаларына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән объектларны чистарту һәм төзекләндерү эшен оештырырга тәкъдим итәргә.
5. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырырга, Интернет челтәренең (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштыруны тәкъдим итәргә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче
А.Х.Сәхибуллин